КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 4

Казан шәһәре, Гагарин урамы, 77 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Социалистик Хезмәт Герое Михаил Васильевич Карпов истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары һәм Татарстан Республикасы Сугыш һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерлары иҗтимагый хәйрия оешмасының Казан шәһәре, Гагарин урамы, 77 нче йорт адресы буенча бина фасадына рус һәм татар телләрендә түбәндәге текст белән М.В.Карповка мемориаль такта урнаштыру турында тәкъдим кабул итәргә:

«В этом доме в 1972 – 2011 гг. жил
Герой Социалистического Труда,
депутат Верховного Совета РСФСР,
слесарь-сборщик Казанского моторостроительного
производственного объединения
Михаил Васильевич Карпов

---

Бу йортта 1972 - 2011 елларда
Социалистик Хезмәт Герое,
РСФСР Югары Советы депутаты,
Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсенең
слесарь-җыючысы
Михаил Васильевич Карпов
яшәде».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның балансча тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин